**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 27 апрелендәге 1410 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2023 елның 19 июлендәге 2031 номерлы**
**«Казан шәһәренең муниципаль маршрутлары буйлап**
**шәһәр автомобиль һәм җир өсте электр транспортында**
**җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә**
**пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында»гы**
**карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәренең муниципаль маршрутлары буйлап шәһәр автомобиль һәм җир өсте электр транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 19 июлендәге 2031 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль маршрутлары буйлап шәһәр автомобиль һәм җир өсте электр транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 22 августындагы 2376 номерлы, 2023 елның 3 октябрендәге 2927 номерлы, 2025 елның 25 июлендәге 2387 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның кушымтасын гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. әлеге карарның кушымтасын Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 19 июлендәге 2031 номерлы карарына кушымта дип санарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 27 апрелендәге
1410 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәренең муниципаль маршрутлары буйлап шәһәр автомобиль һәм җир өсте электр транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруга 2023-2028 елларга планлаштырыла торган чыгымнар турында мәгълүмат**

| Транспорт төрләре | 2023-2028 елларга планлаштырыла торган чыгымнар күләме, сум | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы, шул исәптән | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| Автомобиль транспорты | 1 662 157,04 | 92 849,00 | 331 850,75 | 330 645,00 | 330 486,58 | 330 202,77 | 246 122,94 |
| Җир өсте электр транспорты | 339 000,71 | 19 821,00 | 68 037,00 | 68 255,00 | 68 413,42 | 68 697,23 | 45 777,06 |
| **БАРЛЫГЫ** | **2 001 157,75** | **112 670,00** | **399 887,75** | **398 900,00** | **398 900,00** | **398 900,00** | **291 900,00** |